Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлеге
Сәет авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«15» ноябрь 2025 ел № 2

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Сәмәкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл җирлегенең 01.11.2019 ел «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Сәмәкәй авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында «42/2 номерлы»нигезләмәне раслау хакында", Сәмәкәй авыл жирлеге Сәет авылы гражданнар жыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2026 елда яшәү урыны Сәмәкәй авыл җирлегенең Сәет авылы территориясендә балигъ булган, Сәмәкәй авыл жирлегенең Сәет авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Сәмәкәй авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнарны һәм гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

**- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (зират өчен материал сатып алу һәм киртә кую);**

**-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (чокыр ремонтлау, юллар төзү, вак таш сатып алу, махсус техника хезмәтләре).**

2. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлеге Сәет авылы гражданнар жыены нәтиҗәсен авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Сәмәкәй авыл жирлеге Сәет авылы гражданнар жыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл жирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче.
Сәмәкәй авыл жирлеге Башлыгы И.М.Усманов